**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28март № 193

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яши торган акланган гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 2005 ел, 21 февраль, 104 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы, 2013 ел, 12 март, 157 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Акланган гражданнарга транспортта йөрүгә бәйле булган чыгымнарын каплау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

беренче абзацта «даими теркәлү урын буенча территориаль социаль яклау органы» сүзләрен «даими яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«затның акланган гражданнар категориясенә керүен раслый торган документ күчермәсе».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.15. Әгәр эшкә сәләтле гражданның кереме балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән көндә эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы зурлыгы билгеләнгән Татарстан Республикасында кулланучылар кәрзиненә кертелә торган азык-төлек һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе суммасыннан кимрәк булса, гражданның керемендә балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән көндә эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы зурлыгы билгеләнгән Татарстан Республикасында кулланучылар кәрзиненә кертелә торган азык-төлек һәм хезмәт күрсәтүләр бәясе суммасы исәпкә алына.».

3. Татар ССР Министрлар Советының «Татар ССРда аналарга һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1991 ел, 14 июнь, 261 нче карарына (Татар ССР Министрлар Кабинетының 1992 ел, 12 декабрь, 83 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 17 декабрь, 907 нче, 2003 ел, 23 декабрь, 667 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 – 3, 9,11,12 пунктларны төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\193.docx